**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТУЙМЕТКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул.Школьная, дом 4, с.Туйметкино, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 4 нче йорт, Туймәт авылы, 423108

тел./факс email: 8-(84396) 3-72-90. Tuy.Cmn.2@tatar.ru


**19 сентябрь 2018 ел** **№ 125**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУЙМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Туймәт авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында.**

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Туймәт авыл җирлеге Уставы нигезендә, Туймәт авыл җирлеге Советының 2019 елның 19 сентябрендәге 124 номерлы «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» карарын, Туймәт авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 19 сентябрендәге 37 номерлы «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Шешминка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- Туймәт авылында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юлларны грейдерлауга, урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып

алуга, хезмәтләр күрсәтүгә), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга (хезмәтләр күрсәтүгә));

- Туймәт торак пунктында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, су башнясын буяу, Туймәт торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- мәктәп автобусы өчен тукталыш павильоны урнаштыру;

- Туймәт торак пунктының Мәктәп урамында урам-юл челтәрен төзекләндерү (чокырлар ремонты).

ӘЙЕ ЮК»

3. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» - («Наш Черемшан») район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы,
Туймәт авыл җирлеге Советы рәисе Кәримов Ә. Б.